**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге Олы Яңасала авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

04 нче декабрь 2020 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле узидарә турында” 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 нче елның 04нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Олы Яңасала авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 214 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 112 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы112 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге составына керүче Олы Яңасала авылы халык җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Олы Яңасала авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

**- Шәпкә авылында авыл эчендәге юлларны ремонтлау, чокырлы урыннарга вак таш җәю, таш сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);**

**- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);**

**- корыган агачлар, куакларны кисү, Шәпкә авылы территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү)**» соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. 2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Олы Яңасала авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:
- Шәпкә авылында  авыл эчендәге юлларны ремонтлау, чокырлы урыннарга вак таш җәю, таш сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- корыган агачлар, куакларны кисү, Шәпкә авылы территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);”

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:
-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урам, 1;
-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Шәпкә  авылы, Клуб урамы, 14,шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Шиһабеев